**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында белдерү**

Әлеге белдерү белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итәбез (алга таба – Проект).

Проектның мәгълүмати материаллары:

җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен куллану тәртибе һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү;
шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы;
шәһәр төзелеше регламентлары;
территориаль зоналарның чикләре турында мәгълүматлар, аларда күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында территориаль зоналар чикләренең урнашу урынын график тасвирлау, бу чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге булырга тиеш.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм вакытлары:
Проект буенча гавами тыңлаулар 2025 елның 8 августыннан 2025 елның 23 августына кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы үз эченә түбәндәге этапларны ала:
гавами тыңлаулар башлану турында белдерү;
проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозицияләрен ачу;
проект экспозицияләрен үткәрү;
гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү;
гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Колай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба Колай авыл җирлеге) территориясенең Колай авылы, Олы Дүртөйле авылы, Арышхазда авылы, Тагашево авылы, Карповка поселогы торак пунктлары өлешендә үткәрелә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
Гавами тыңлауларда катнашучылар булып торалар:
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларын хокуклы биләүчеләр;
күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокуклы биләүчеләре.
Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларның датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Олы Дүртөйле авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 11 сәгать 00 минутта,: ТР, Питрәч районы, Олы Дүртөйле авылы, Кооператив урамы, 2А йорт адресы буенча;

- Колай авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 11 сәгать 30 минутта Колай авыл мәдәният йортының тамаша залында, ТР, Питрәч районы, Колай авылы, Чкалов урамы, 1А йорт адресы буенча;

- Арышхазда авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 13 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 15А йортындагы ФАП бинасы янында, ТР, Питрәч районы, Арышхазда авылы, Үзәк урамы, 15А йорт адресы буенча;

- Тагашево авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 13 сәгать 30 минутта Космонавтлар урамы, 51А йортындагы кибет янында, ТР, Питрәч районы, Тагашево авылы, Космонавтлар урамы адресы буенча;

- Карповка поселогы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 14 сәгать 00 минутта авыл клубы бинасында, ТР, Питрәч районы, Карповка поселогы, Совет урамы, 37А йорт адресы буенча.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының экспозициясен оештырырга:

2025 елның 15 августыннан 2025 елның 19 августына кадәр Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://pestreci.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-8028709.htm .

- 2025 елның 19 августында Олы Дүртөйле авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 11 сәгать 00 минутта, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Олы Дүртөйле авылы, Кооператив урамы, 2А йорт; Колай авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 11 сәгать 30 минутта Колай авыл мәдәният йортының тамаша залында, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Колай авылы, Чкалов урамы, 1А йорт; Арышхазда авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 13 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 15А йортындагы ФАП бинасы янында, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Арышхазда авылы, Үзәк урамы, 15А йорт; Тагашево авылы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 13 сәгать 30 минутта Космонавтлар урамы, 51А йортындагы кибет янында, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Тагашево авылы, Космонавтлар урамы;

Карповка поселогы халкы өчен: 2025 елның 19 августында 14 сәгать 00 минутта авыл клубы бинасында, адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Карповка поселогы, Совет урамы, 37А йорт.

2025 елның 15.08 дән 19.08.2025 г. кадәрге чорда катнашучылар җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия:

язма рәвештә яки электрон документ формасында гавами тыңлаулар оештыручысы адресына түбәндәге адрес буенча: 422776, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Колай авылы, Профсоюз урамы, 24А йорт, e-mail: Kul.Pes@tatar.ru;

проект экспозициясен карап чыгучыларны исәпкә алу китабында (журналында) язу аша - Олы Дүртөйле авылы халкы өчен адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Олы Дүртөйле авылы, Кооператив урамы, 2А йорт; Колай авылы халкы өчен адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Колай авылы, Чкалов урамы, 1А йорт; Арышхазда авылы халкы өчен адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Арышхазда авылы, Үзәк урамы, 15А йорт; Тагашево авылы халкы өчен адрес буенча: ТР, Питрәч районы, Тагашево авылы, Космонавтлар урамы.

гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәргәндә язма яки телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдим яки искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында мәгълүмат бирәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туган көне, яшәү урыны адресы (теркәлү) – физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адресы – юридик затлар өчен) мондый мәгълүматларны раслаучы документлар кушымтасы белән.

Тиешле җир кишәрлекләренең һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының һәм (яки) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре булып торучы гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга аларның хокукларын билгели яки раслый торган башка документлар тапшыралар.

Тәкъдимнәр яки искәрмәләр керткәндә, гавами тыңлауларда катнашучылар «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыга үзләренең катгый ризалыгын бирәләр.

Әлеге белдерүне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://parvo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Әлеге белдерүне «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru ), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://parvo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская